КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 март г.Казань № 130

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибен раслау турында» 2018 ел, 21 декабрь, 1202 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 июль, 589 нчы; 2020 ел, 26 ноябрь, 1066 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аларны аерым җыю) тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Электрон җиһазлар калдыкларын җыю»;

5.1 – 5.4 пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин